


Мәктәп укытучылары укыту эше белән мәшгуль булуларына карамастан, дәрестән сон балалар белән театр репетицияләре vткәрәләр, купшы костюмнар һәм реквизитлар әзерлиләр, киләчәктә тамашачыларга нинди спектакльләр kvрсәтеләчәге турында уйланалар...
Әле генә Аксен урта мәктәбе базасында «Ачык сәхнә» III республика мәктәп театрлары конкурсынын муниципаль этабы vтте. Конкурс дvрт яшь торкеме, дvрт номинация буенча - драма театры, музыка театры, курчак театры, «Минем Пушкин» бәяләнде. Әлеге театр ярышынын нәтижәләре билгеле инде.       Шулай итеп, «Драма театры» номинациясендә (катнаш торкем) Константин Сергиенконын повестена сәхнәләштергән «Этләр» пьесасы белән Ләмберәнен икенче урта мәктәбеннән «Овация» театр коллективы жинvче булды. Торкем житәкчесе - Е.А. Лобурева.
Бу номинациядә призерлар булып ике коллектив танылды: Аксен урта мәктәбеннән А.Ш.Абдюшева житәкчелегендә Нәфис Әхмәтнен «Әти, жаным!» һәм Чирмеш топ мәктәбеннән Л.Н.Петрова житәкчелегендәге коллективлар.
«Драма театры (11 яшькә кадәр) номинациясендә Берсеневка урта мәктәбенен Н.В.Дроздова житәкче-легендәге «Созвездие» театр коллективы жинvче булды.
«Курчак театры» номинациясендә Л.М.Искандярова житәкчелегендә «Колобок на современный лад» белән Ләмберәнен беренче урта мәктәбенен «Мозаика» театр коллективы жинvче булды.
«Драма театры» номинациясендә (15-18 яшь) К.Н.Шишканова һәм И. А. Симонова житәкчелегендә Александровка урта мәктәбеннән призер дип танылды.
Муниципаль турда жинvчеләргә кон-курснын республика этабын читтән торып узарга туры киләчәк, шуна әзерләнәләр. Мәктәп театрлары житәк-челәре нәрсә сойли, шуна kvз салыйк…
Альфия Абдюшева, Аксеново урта мәктәбе татар теле укытучысы:
- Безнен «Беренче театр» 2022-2023 уку елында тозелде. Узган ел без «Идел йолдызлары» Тобәкара татар әдәбияты фестивалендә һәм «Идел буе театраль» фестиваленен округ этабында катнаштык. Ижат ярдәмендә безнен яшь актерларыбыз югары сәнгатькә ияләшә һәм ботен гvзәллекне чын-чынлап бәяләvчеләргә әверелә.

Мәктәп театры нәрсәдән башлана дигән сорауга мин болай дип җавап бирәм: балалар һәм олкәннәр vз тормышларын яктырак, матуррак, кызыклырак итәргә, рухи яктан баерга, сәнгать ярдәмендә башка мәдәниятне белергә һәм анларга теләv. Икенче яктан, барыбер мәктәп театрларын «профессиональләштерv» белән арттырып җибәрмәскә һәм шунын белән аларны чиста балалар шатлыгыннан мәхрvм итмәскә кирәк.
Ә Лиана Искандярова, Ләмберә беренче мәктәбе укытучысы укучылар театры турында болай ди:
- Мин башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшлим. Узган муниципаль конкурста без экспертларга «Колобок на современный лад» дигән кызыклы спектакль кvрсәттек. Укучыларымнын спектакльдә курчаклар белән оста идарә итvләреннән, vз рольләрен чын-чынлап дорес итеп уйнарга тырышуларыннан бик канәгать калдым. Әкияттә беренче сыйныф укучыларымнын унысы катнашты. Алар минем әлегә кечкенә: кайберләре әле бик авыр укый, әмма спектакльләрдә уйнарга бик ярата! Тыйнакланып тормыйм, тәрбияләнvчеләремнен ин артистларын атыйм. Болар - игезәк апалы-сенелле Ангелина һәм Эвелина Ермолаевлар, Эмиль Сакаев, Кира Кулемина. Доресен генә әйткәндә, минем ботен беренче сыйныфым бvген театр репетицияләренә тартыла. Бу мине бик шатландыра һәм илһамландыра.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**